**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июль № 497

г. Казань

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» 2016 елның 21 маендагы ПУ-491 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру өлкәсендә бердәм сәясәтне, шулай ук Татарстан Республикасында архив эше белән идарә итү өлкәсендә мөнәсәбәтне формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә, гражданнарның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең объектив, дөрес мәгълүматка ихтыяҗын тәэмин итү өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм файдалануны аның эшчәнлеген төп максаты итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына:

Учреждениенең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәүгә алырга, бүтән зарур оештыру чараларын үткәрергә;

Учреждение уставы расланганнан соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеген, шулай ук күчемсез милек объектларына техник документларны тапшырырга;

ел саен Учреждение өчен, аның уставта каралган төп эшчәнлек төре нигезендә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт биремен расларга.

3. Учреждение тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен башкаруны финанслар белән тәэмин итү Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Учреждениегә каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение уставы расланганнар соң билгеләнгән тәртиптә 30 көн эчендә Учреждениегә оператив идарә итү хокукында аның эшчәнлеген тәэмин итәр өчен кирәкле, шул исәптән аеручы кыймматле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен беркетергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән берлектә әлеге карарның 2 – 4 пунктлары үтәлгәннән соң 60 көн эчендә Учреждениенең хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга норматив чыгымнарын раслау турында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раславына кертергә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин